ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2022 Олы Кайбыч ав. № 128

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды күләме «Тиешле елга Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» Кайбыч муниципаль районы Советы карарлары белән билгеләнә һәм күрсәтелгән карарлар белән расланган чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан арта алмый.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров